# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«16» 11 2021 № 4155

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 сентябрендәге «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 4049 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 сентябрендәге «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 4049 номерлы карарына 2 таблицаның 1,2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1. | Авыл җирлегендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан рус телендә белем бирми торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларга рус телен өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0 |
| 2. | Рус телендә белем бирүче мәктәпкәчә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларга туган телне (татар, чуаш, мари һ.б., рус теленнән тыш) өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында

һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин